**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 14 июль № 479

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 21 август, 603 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 21 август, 603 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 февраль, 87 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт контролен (дәүләт экология контролен) гамәлгә ашыру турында» 2009 елның 27 гыйнварындагы 53 нче карары белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль дәүләт экология күзәтчелеге турында» 2014 елның 8 маендагы 426 нчы карары белән» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибендә:

5 пунктта «һәм капиталь ремонт» сүзләрен төшереп калдырырга;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт инспекторлары булган дәүләт күзәтчелеге органнары вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләргә хокуклы:

тикшерү үткәрү барышында кирәк булган мәгълүматны һәм документларны мотивлашкан язмача соратулар нигезендә дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән һәм гражданнардан соратырга һәм алырга;

хезмәт таныклыгын һәм тикшерү билгеләү турында дәүләт күзәтчелеге органы җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) боерыгы (күрсәтмәсе) күчермәсен күрсәтеп, каршылыкларсыз юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм гражданнар хуҗалык һәм бүтән эшчәнлекне тормышка ашырганда файдалана торган территорияләргә

биналарга, урыннарга, корылмаларга, шул исәптән чистарту корылмаларына керергә һәм аларны тикшерергә, шулай ук контрольдә тоту буенча кирәкле караулар, сынаулар, үлчәүләр, тикшеренүләр, экспертизалар һәм башка чаралар үткәрергә;

юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм гражданнарга мәҗбүри таләпләрне билгеле булган бозуларны бетерү турында, үсемлекләргә, хайваннарга, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт һәм муниципаль мөлкәткә зарарны булдырмый калуны тәэмин итү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне булдырмау буенча чаралар үткәрү хакында күрсәтмәләр бирергә;

мәҗбүри таләпләрне бозу белән бәйле административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә, әлеге административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерергә һәм мондый бозуларны булдырмый калу чараларын күрергә;

җинаять билгеләре буенча җинаять эшләре кузгату турында мәсьәләләрне хәл итү өчен әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә законнар бозу белән бәйле материалларны вәкаләтле органнарга җибәрергә;

мәҗбүри таләпләрне бозу нәтиҗәсендә әйләнә-тирә мохиткә һәм аның компонентларына китерелгән зыянны кайтару турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаятьләр бирергә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин